СОВЕТ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче Май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 1-42 — от 31.01.2025

# Об отчете Главы Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района о работе в 2024 году и задачах на 2025 год

Заслушав и обсудив отчет Главы Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района Зиатдинова А.И. о работе в 2024 году и задачах на 2025 год, Совет Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района отмечает, что Глава Поселения, осуществляя полномочия высшего должностного лица муниципального образования, действовал в соответствии с Конституциями Российской Федерации и Республики Татарстан, Федеральным законом от 06.10.2003 года №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28.07.2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Уставом муниципального образования Усалинское сельское поселение Мамадышского муниципального района Республики Татарстан.

Приоритетными направлениями в жизнедеятельности Поселения оставались: сохранение общественно-политической стабильности, формирование нормативных, правовых, организационных и социально-экономических условий для развития местного самоуправления, осуществления мер по обеспечению достойного уровня и качества жизни населения района, укрепление межнационального, межконфессионального и гражданского согласия.

Исходя из вышеизложенного, а также руководствуясь положениями Устава муниципального образования Усалинское сельское поселение Мамадышского муниципального района Республики Татарстан о подконтрольности и подотчетности Главы Поселения перед населением и Советом Поселения, Совет Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района Республики Татарстан р е ш и л:

1.Отчет Главы Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района Зиатдинова А.И. о работе в 2024 году и задачах на 2025 год принять к сведению.

2. Депутатам Совета Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района довести отчет Главы Усалинского сельского поселения

Мамадышского муниципального района до сведения избирателей в своих округах.

3. Рекомендовать Исполнительному комитету Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района:

- разработать план мероприятий по выполнению замечаний и предложений, высказанных в отчетном докладе и при его обсуждении, и информировать депутатов в срок до 1 мая 2025 года;

- принять меры для обеспечения развития предпринимательства во всех отраслях экономики Поселения;

- обеспечить повышение качества жизни населения на основе устойчивого, динамичного развития экономики и создания благополучной среды для граждан;

-обеспечить развитие личных подсобных хозяйств в населенных пунктах района, реализацию программ по строительству семейных ферм;

- совместно с правоохранительными органами вести дальнейшую работу по повышению уровня общественной безопасности, жизни, здоровья и достоинства граждан, частной государственной и муниципальной собственности с максимальным использованием местного потенциала;

- продолжить мероприятия по благоустройству, озеленению и санитарной очистке населенных пунктов, обеспечению экологической безопасности;

4. Опубликовать отчетный доклад Главы Мамадышского муниципального района на информационных стендах поселения и разместить на официальном сайте Мамадышского муниципального района РТ в информационно-телекоммуникационной сети Интернет по веб-адресу: http://mamadysh.tatarstan.ru., официальном портале правовой информации Республики Татарстан (pravo.tatarstan.ru)

5. Контроль за исполнением настоящего решения возложить на Главу Усалинского сельского поселения Мамадышского муниципального района Зиатдинова А.И.

Глава, председатель Совета
Усалинского сельского поселения
Мамадышского муниципального района ____________ А.И.Зиатдинов

Приложение № 1

# ОТЧЕТ
# ГЛАВЫ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
# ЗА 2024 ГОД

Хәерле көн , хөрмәтле Вадим Ильич, Марат Готович коллегалар, депутатлар, җыелышта катнашучы иптәшләр! Рөхсәт итегез сезне Усали авыл җирлегенең 2024 нче елда эшләнгән эшләренә нәтиҗә һәм 2025 нче елга планнары турындагы отчетым белән таныштырып узарга.

Усали авыл җирлеге Советы, үзенең эшчәнлеген, Усали авыл җирлеге Уставына, Совет Регламентына һәм 2024 нче елга төзелгән переспектив планга нигезләнеп эш итә.

Усали авыл җирлеге барлыгы 6 авылны берләштерә:

- Усали
- Югары Кыерлы
- Владимир
- Бүрсет-Сукачы
- Дружба
- Күк Чишмә

Территориядә 1 урта, 1 төп, 1 башлангыч мәктәп , 1 балалар бакчасы, 1 авыл мәдәният йорты, 2 авыл клубы, 2 китапханә, 1 амбулатория, 4 мед.пункт, 2 почта бүлеге, 5 кибет, 3 мәчет халыкка хезмәт күрсәтә.

Усали авыл җирлегендә 427 хуҗалык исәпләнелә һәм 1011 кеше исәптә тора, шуларның 722 е шушы җирлектә яши: 510 е хезмәткә яраксыз яшьтәге кешеләр, 405 е пенсионерлар, 32 кеше пенсия яшенә кадәрле группадагы инвалидлар, 16 студент, хезмәт ветераннарыбыз -149, тыл хезмәтчәннәре – 16, тол хатыннар – 4, балалар бакчасы яшендә 8, мәктәп яшендәге 47 бала исәпләнелә. Бүгенге көндә җирлектән **4** егетебез илебезнең төрле почмакларында үзләренең хәрби бурычларын үтиләр, Махсус хәрби операция барышында 3 егетебез Украинада.

Бюджет оешмаларында - 71, төрле тармакларда – 138 кеше эшли.
2024 нче елда җирлегебездә 21 кеше вафат булды, 1 бала туды.
Шулай ук 2024 нче елда Үсәли авылына 4, Владимир авылына 1 гаилә күчеп кайтты. Барлыгы 16 кеше, шулар арасында 2 мәктәпкәчә яшьтәге бала, 5 укучы, 1 студент.

Һәр календарь яңа ел башланыр алдыннан, авыл җирлеге бюджетын формалаштыру Һәм раслау уздырыла.

2024 нче елда бюджетыбыз 7 миллион 292067,78 сумны тәшкил итте. Шуннан үз керемнәребез 1 миллион 837939 сум, 115,4% дәүләттән бирелгән дотацияләр 2 миллион 698541 сумны, субвенция- 116300, межбюджетный трансферт- 2 миллион 511287 сумны тәшкил итте. Үтәлеш 102 % .

Усали авыл Советы депутатлары тарафыннан 2024 нче елда барлыгы 9 утырыш уздырылды, бу утырышларда 131 нче Федераль Законга һәм авыл җирлеге Уставына нигезләнеп авыл җирлеге администрациясе, эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча 24 сорау каралды. Советта бүгенге көндә 10 депутатыбыз эшләп килә

Шулай ук үзебезнең рәсми сайтыбыз да бар: бу сайтта бюджет үтәлеше, Совет эшчәнлеге, административ регламентлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне оештыру турындагы мәгълүматләрне, җирле үзидарә органнары кабул итә торган норматив-хокукый актларны, шулай ук гәвами тыңлаулар узуы турындагы мәгълүматлар һәм ничек узуы турындагы заключениеләр урнаштырылып барыла. Шулай ук җирлегебездә булган барлык яңалыклар да рәсми сайтыбызда чагылыш таба. Теләге булган һәр кешенең дә моның белән танышып бару мөмкинлеге бар.

Авыл җирлегендә халыкны кабул итү, халыкның мөрәҗәгатьләрен карау, тиешле тәртиптә алып барыла. 2024 нчы елда халык соравы буенча барлыгы 66 справка-белешмә бирелде. Барлык мөрәҗәгатьләр дә уңай хәл ителде.

Төрле эчтәлектәге 55 хатлар, характеристикалар бирелде, 9 нотариаль эшләр башкарылды. 2024 нче елда җирлек администрациясенең электрон документ әйләнешенә 347 документ килде, күбесе аның вакытында башкарып, җавап бирәсе документлар. Ел әйләнәсенә барлыгы 49 документ әзерләп җибәрелде. Электрон почта аша килгән барлык 132 запрос, сообщениеләр һәм хатларга 62 җавап язылды, шулай ук электрон халык почтасы эшли, 5 халык мөрәҗәгатенә җавап язылды. Халыктан килгән мөрәҗәгатләрнең күбесе су белән тәэмин ителеш, чүп җыюга карата, шулай ук урамдагы багана утларының янмавына кагылышлы сораулар булды, барсы да уңай хәл ителде.

Авыл хуҗалыгы

Усали авыл җирлегендә 322 баш мөгезле эре терлек исәпләнелә, 322 мөгезле эре терлекнең 184 е савым сыерлар, 10 хуҗалыкка 4 сыер туры килә. Авыл җирлегендә 212 сарык, 19 кәҗә , 2119 баш тавык, 287 баш умарта исәпләнелә. Җирлек буенча иң күп мөгезле эре терлек тотучы кешебез булып Владимир авылыннан Бачков Владимир Дмитриевич тора, бүгенгесе көндә анын хуҗалыгында 15 баш савым сыер, Кушаев Александр Николаевич хуҗалыгында 10 баш савым сыер. Шулай ук Берсут Сукачи авылыннан Шамсутдинов Раиль Фарзетдин улынын шәхси хуҗалыгында 15 баш МЭТ , 10 баш савым сыеры бар, Үсәли авылында Гарапов Айрат Сабирзянович хуҗалыгында – 7, Ахтямов Рөстәм Исмагилович хуҗалыгында - 6 Владимир авылыннан Малов Валерьян Дмитриевич хуҗалыгында 5 баш савым сыер, 4 баш бозау, үгезләр, Усалидан Имамутдинов Ильшат Рафкатович, Имамутдинов Ильшат Рафкатович , Югары Кыерлыдан Сабирҗанов Илшат Газизҗанович, Берсут-Сукачидан Садыков Фәрит Музипович хуҗалыкларында МЭТ нең саны дистәгә тула.
Усали авыл җирлегендә халыктан сөт җыю ИП Давлетшина Әлфия тарафыннан башкарыла.

2024 нче елда
Усалида 1054 ц ны тәшкил итә.
Югары Кыерлыда 876 ц
Владимирда 1895 ц
Берсут-Сукачида 530 ц 32 сум бер л.

Һәр көнне иртәнге сәгатьләрдә машина һәр авылга килеп сөтләрне җыеп алып китә, сөт тапшыручылар белән вакытында исәп-хисап ясалып бара.
2024 нче ел күрсәткечләренә йомгак ясап Үсәли авыл җирлеге буенча иң күп сөт тапшыручылар булып

**Владимир авылыннан**
**Бачкова Елена Петровна – 52990л**

**Югары Кыерлы авылыннан**
**Зиатдинова Гөлнара Хатыйповна – 16456л**

**Усали авылыннан**
**Ахтямова Илһамия Гилметдиновна – 13317л**

**Берсут- Сукачи авылыннан**
**Шамсутдинов Раиль Фарзетдинович – 12859л**

Хөрмәтле, авылдашлар! Беребезгә сер түгел, көннән –көн авылдагы яшәүчеләрнең  яшьләре олыгая, ләкин шуңа да карамастан , сыер саннарын киметмичә , ит,сөт тапшыруларны берничә ел рәттән киметмичә баруыгыз - сезнең авыр хезмәтегезнең нәтиҗәсе ул, хөрмәтле авылдашлар.
Сезгә авыр хезмәтегездә уңышлар телибез, иң беренче чиратта гаиләләрегезгә исәнлек-саулык, мал-туарларыгызга тазалык, көрлек, югары продуктлылык телисе килә, алдагы көннәрдә дә шушы темпта эшләргә язсын.

2022нче елда Югары Кыерлы авылында  авылдашыбыз  Газизов Булат Гаптелкадыйрович  крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып атлар үрчетү белән шөгыльләнә башлады. 2023 нче елда бу хуҗалык “ЭКОБЕРСУТ” кооперативына берләштерелде, бүгенгесе көндә  74 аты бар.
Бүгенгесе көндә шәхси хуҗалыкларда  53 трактор,  2 шәхси камаз , 37 берәмлек төрле авыл хуҗалыгы техникасы исәптә тора, бигрәктә  Владимир, Усали авылларында шәхси хуҗалыкларда печән чапкычлар, әйләндергечләр, җыйгычлар күп  Шулай ук халыкның тормыш көнкүреш дәрәҗәсенең үсешенә аерым җир хуҗаларының пай җирләрен  рәсмиләштереп файдаланулары да зур йогынты ясый.
Владимир авылыннан Петров Николай Васильевич, Малов Валерий Дмитриевич, Кушаев Александр Николаевич, Юзеев Валерий Михайлович Усалидан Хайбуллин Вәкил  Музипович, Хайбуллина Әлфия Габрафиковна , Имамутдинов Ильшат Рәфгатовичлар үзләренен  пай җирләрен эшкәртеп, җирлек халкын печән, салам, ашлык белән тәэмин итеп торалар.  Бүгенге көндә “Агроинпекс  Казыли “ крестьян фермер хуҗалыгы  пай җирләрен эшкәртеп, халыкка 2024 нче елда  3ц  икмәк бирде, бу да халыкка  ярдәм булды, бик зур рәхмәт аларга.

Бүгенгесе көндә җирлектә теркәлгән 34 мәшгуль( самозанятый) кеше бар.

Халыкны социаль яклау өлкәсе

Усали авыл җирлегендә  халыкны социаль яклау буенча даими рәвештә   эш алып барыла. Бугенгесе кондә Усали авыл  җирлегендә  119 ялгыз яшәүче кеше , шулай ук  олкән яшьтәге 41  парлы гаилә исәпкә  алынган. Без алар белән һәрвакыт даими элемтәдә,  сорауларын тыңлап, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз.  Ярдәмгә мохтаҗларга
3 социаль хезмәткәр ярдәм күрсәтәләр. Аларның эшләре һәр яктан уңай бәяләнә,
Бөек  Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне һәм юбилярларны котлаулар  безнең җирлектә   матур итеп оештырыла.

Хөрмәтле иптәшләр! 2014 нче елдан башлап халыктан үзара салым акчасы җыела башлады, һәм шул җыелган акчаларга республика бюджетыннан яңадан 4 кә тапкырланып авыл җирлеге бюджетына акчалата ярдәм бирелеп, бик тә күп эшләр башкарылды.
2024 елда – 1 698800 сум

Шушы дәвердә авылларыбыздагы зиратлар, чишмәләр, һәм иң мөһиме авыл эчендәге юллар ремонтланды. 2024 нчы елда түбәндәге эшләр башкарылды:

1. Җирлек буенча 42 баганада яктырткычлар алмаштырылды;
2. Усали торак пунктында су белән тәэмин итү системасы ремонтланды; карт агачлар киселде;
3. Усали торак пунктында Беренче Май һәм Комсомол урамнарында вак таш белән капланган юлның чокырлары ремонтланды;
4. Югары Кыерлы торак пунктындагы Җиңү урамында вак таш белән капланган юлның чокырлары ремонтланды;
5. Бөрсет-Сукачы торак пунктындагы Җиңү һәм Яшьләр урамында вак таш белән капланган юлның чокырлары ремонтланды;
6. барлык торак пунктларда юлларны тигезләү һәм кардан чистарту башкарылды;
7. - барлык торак пунктларда лампалар, яктырту җиһазлары кайтартылды.
8. Владимир авылында тау башындагы чишмә төзекләндерелде һәм авылның су системасына тоташтырылды.

А.П. Аксаков көче белән Владимир авылында көтү йөри торган һәм сабантуй мәйданына чыгучы күпер төзелде. Шулай ук Владимир клубына өлешчә ремонт ясалды, нигезе ныгытылды, яңа җылыту системасы куелды, керә торган ишек тимердән куелды.
Югары Кыерлы клубында өлешчә ремонт эшләре Хисматуллин И.Н. ярдәме белән башкарылды.

2025 нче елда да үзара салым акчасының бер кешегә җыелу суммасы һәр авылда төрлечә һәм 500 сумнан 800 сумга кадәр тәшкил итә. Бу эш башланып китте, форсаттан файдаланып, барыгызның да актив катнашуын сорыйм.
2025 нче елда узара салым акчасын нинди максатларда тотылачагын һәр авылда уздырылган халык җыеннарында тикшереп, уртак фикергә килдек. Бу турыда һәммәгез дә хәбәрдар.

Сәламәтлек саклау өлкәсе

Мифтахутдинов Нургаяз Касимович җитәкчелегендәге Усали амбулаториясе 13 авыл халкына медицина ярдәме күрсәтә. биредә 1 гомуми практика врачы, 1 теш табибы, 5 шәфкать туташы, 1 санитарка , авыллардагы 4 медпункт фельшерлары халыкка армый-талмый медицина ярдәме күрсәтәләр, һәркайсы вазыйфаларын тиешле югарылыкта башкаралар. Шулай ук диспансеризация узу да 2024 елның башыннан тулы куәтенә башланды. Кай вакыт та барсаң да , амбулаториядә халык медосмотр уза.Бу бик мөһим, моңа һәркайсыбыз уңай карап, вакытында диспансеризацияне узуыгызны, прививка ясатуыгызны сорар идем, бу бары тик үзебезнең сәламәтлегебез өчен кирәк.

Мәгариф, белем бирү өлкәсе

2024/2025 нче уку елында Усали урта белем бирү мәктәбендә 41 укучы белем ала, 16 педагог, 10 тех.персонал эшли. Шулай ук Владимир белем бирү мәктәбендә 6 бала белем ала. Мәктәпләрдә бушлай төрле фән, спорт, шулай ук бию түгәрәкләре дә алып барыла. Спорт өлкәсендә, мәдәният өлкәсендә шактый гына яхшы күрсәткечләребез бар.

Белгәнегезчә үзара салым программасына нигезләнеп, 2017 нче елда авылларда урамнарга 262 данә экономияле яктырткыч куелган иде. Узган елда җирлек буенча 42 яктырткыч алыштырылды Халыктан алынган иң күп гозер дә шушы багана утлары хакында, ләкин яктырткычлар урында төзәтелми, Казанга алып барып , ремонтлатып алып кайтырга кирәк. Шушыларны исәпкә алып 2025 елда да үзара салым акчасын яктырткычларны ремонтлау өчен дә тотачакбыз.

Усали авыл җирлегендә 5 зират бар. Барлык авылларның зиратлары да игътибар үзәгендә тора. Җирлектәге һәрбер авылның да зираты коймалар, тимер сеткалар белән әйләндерелеп алынган. Тузган өлешләрен һәр елны төзекләндереп торабыз. Авыл халкы көче белән өмәләр даими үткәрелә, зиратларны корган агачлардан чистартып торабыз.

Шулай ук җирлегебездә чишмәләребез бик күп. Чишмәләребез кулдан килгәнчә төзекләндереп торыла. Бүгенге көнгә 15 чишмә төзекләндерелде.
Казан һәм Мамадыш шәһәрләрендә үткәрелүче ярминкәләрдә бик күп катнашабыз. Алып барган барлык товарларыбызны да сатып бетереп кайтабыз.
2024 елда данлыклы Өчөйле базары традицияләрен яңартып, авылыбыз җирлегендә дә ярминкәләр оештырылды.

Шулай ук халыкны печән белән тәэмин итү, халыкны өзлексез су белән тәэмин итү өстендә эшләү - планда беренче урында тора. Шулай ук кыш көннәрендә урамнарны кардан чистарту, юллар ачу өстендә дә һәрдаим эшләргә кирәк. Урам утларын ремонтлап, алыштырып тору да көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Чыгышымны тәмамлап шуны әйтәсем килә, җирлектәге эшне халык белән берлектә эшләгәндә генә ниндидер уңай нәтиҗәләргә ирешеп булачак. Килеп туган проблемаларны вакытында, төгәл итеп урыннарда хәл итәргә тырышабыз һәм тырышачакбыз.Чөнки безнең команда бик көчле һәм һәрбер эшебезне киңәшләшеп бергә-бергә башкарабыз. Шушы уңайдан барлык бюджет оешмаларында эшләүче коллегаларга зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Алга таба да шушы юнәлешләрне тагын да камилләштереп, замана белән бер аяктан атларга, районыбыз җитәкчелеге белән берлектә, аңлашып, уңышлы гына эшләргә насыйп булсын иде дигән теләктә калам. Барыбызга да сәламәтлек, уңышлар, гаиләләребезгә, илебезгә иминлек, тынычлык теләп калам.

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт !